| СОВЕТ ТУМБАРЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОМБАРЛЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30 октябрь 2024 ел Татар Томбарлысы авылы № 129

Баулы муниципаль районы
Томбарлы авыл җирлеге Советының
"Җир салымы турында" 17.11.2020
№8 карарына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Томбарлы авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Баулы муниципаль районы Томбарлы авыл җирлеге Советының «җир салымы турында» 17.11.2020 №8 карарына (17.02.2021 №13, 20.12.2022 №61, 22.05.2023 №82, 05.10.2023 №98 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

2 пункттагы 2 һәм 3 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегенең өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата, моңа әлеге абзацта күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), эшкуарлык

эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләре һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләре;

3) шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм аерым Россия Федерациясе закон актлары», әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, аларның һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә»;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында pravo.tatarstan.ru һәм Баулы муниципаль районының рәсми сайтында bavly.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма алар рәсми басылып чыккан көннән кимендә бер ай узгач һәм чираттагы салым чорының 1 числосыннан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Томбарлы авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе

А.М. Миназова